СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«5» июль 2018 ел № 92

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга (соңгы үзгәрешләр белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, шулай ук «Прокуратура органнарының хокук чыгару эшчәнлеге һәм дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне яхшырту турында» 2007 елның 17 сентябрендәге 144 номерлы Россия Федерациясе Генераль прокуроры боерыгына туры китереп, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2018 елның 13 апрелендәге 258-И номерлы бәяләмәсен өйрәнеп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 79,80,81 статьясы нигезендә, Норма авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хупларга (1 нче кушымта).

2. Муниципаль берәмлек Уставына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә Норма авыл җирлеге Советы депутатларының һәм гражданнарның Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәрен өйрәнү һәм гомумиләштерү эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга. (2 нче кушымта)

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл

җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибен расларга. (3 нче кушымта)

5. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркемгә эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр Ф.И.А, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, түбәндәге адрес буенча җибәрелә: Норма авылы, М. Җәлил урамы, 2а нчы йорт, Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары кабинеты.

6. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлауларны түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Норма авылы, М. Җәлил урамы, 2а нчы йорт.Гавами тыңлауларны үткәрү датасы: 2018 елның 23 августы.

7. Әлеге карарны baltasi.tatar.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Норма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Норма авыл җирлеге башлыгы урынбасары Р.Х. Галимовка йөкләргә.

Рәислек итүче
Норма авыл җирлеге Советы депутаты С. М. Исрафилов